وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№19 (136). 11 май 2012 / 20-җөмәдел-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ






Мәктәпләргә яңа фән кертелә ▷2◁



Мәчетләр язмышында – татар язмышы ▷2-3◁



Вәсвәсә уйлардан арына алмыйм... ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАЗАННЫҢ 7 НЧЕ ШӘҺӘР ХАСТАХАНӘСЕНДӘ НАМАЗ УКУ БҮЛМӘСЕ АЧЫЛДЫ

4 майда Казанның Чуйков урамында урнашкан 7 нче шәһәр хастаханәсендә намаз уку бүлмәсе ачылды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең нәшрият бүлеге җитәкчесе, башкалабызның Тынычлык мәчете имамхатыйбы Камил хәзрәт Сәмигуллин сүзләренә караганда, намаз бүлмәсен ачу тантанасында догалар укылган, вәгазь сөйләнгән. "Намаз бүлмәсе бик матур, уңайлы. Авырулар да, аларның якыннары да биредә иркенләп намаз укый, күңелләренә тынычлык таба ала. Күршедә православ дине вәкилләре өчен дә аерым бүлмә булдырылган", - диде Камил хәзрәт.

Белгәнебезчә, күп еллар дәвамында Төбәкара клиника һәм диагностика үзәгендә (МКДЦ) һәм Республика клиник хастаханәсендә (РКБ) намаз уку бүлмәләре эшләп килә. Махсус намаз бүлмәсе булдыру ул - авырулар хәленә керү, аларның күңелләрен юату, дин аша бер шифа табу булып тора. Бүгенге көндә сәламәтлек саклау учреждениеләрендә намаз бүлмәләре ачу сәламәтлек саклауга кагылышлы яңа кануннар нигезендә хуплана гына.

### ӘГЕРҖЕДӘ БАШЛАНГЫЧ ДИНИ БЕЛЕМ АЛУЧЫЛАР САНЫ АРТА

Әгерже районы Җәмигъ мәчетендә мөхтәсибәт каршында эшләп килүче мәдрәсә шәкертләренең чыгарылыш кичәсе булды. Әлеге тантаналы чарада район башлыгы Фәрит Габбасов, Әгерже районы имам-мөхтәсибе Ранил хәзрәт Якупов һәм мәдрәсә мөгаллимнәре катнашты.

Имам-мөхтәсиб Ранил хәзрәт Якупов билгеләп үткәнчә, мәдрәсәдә бүгенге көндә 170 шәкерт башлангыч дини белем ала. Чыгарылыш шәкертләре - мәдрәсәнең беренче карлыгачларының саны 52 гә җиткән.

### ИСЛАМ КИТАП КҮРГӘЗМӘ-ЯРМИНКӘСЕ УЗАЧАК

Казанда Мәрҗани мәчете янындагы мәйданда урнаштырылган чатырда 2012 елның 7-11 июнендә бишенче тапкыр Бөтенроссия Ислам китап күргәзмә-ярминкәсе үтәчәк.

Китап күргәзмәсе Россиядә Ислам темасына китаплар нәшер итүне цивилизацияле рәвештә үстерү һәм китап укучыларны илдәге мөселман китапларын бастыручы нәшриятлар белән якыннан таныштыру максатыннан оештырыла. Бу эшкә Казан мөхтәсибәте алынды.

Күргәзмәдә Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Түбән Кама, Уфа, Екатеринбург, Түбән Новгород һәм Махачкала шәһәрләреннән егермегә якын ислам нәшрияты катнашыр дип көтелә. Китаплар нәшрият бәяләре белән сатылачак.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***


**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**


# ФИКЪҺЕ БЕЛГЕЧЛӘРЕ (ФАКИҺЛӘР) НИНДИ ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛЕНӘЛӘР?

*Рәхмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән. Бөтен галәмнәрнең, барча халыкларның гадел хуҗасы, тәрбиячесе Аллаһка шан-шәрәфләр, дан вә мактаулар булсын!*

*Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикере буенча, фикъһе белгечләре (факиһләр) 7 төркемгә бүленәләр:*

*1. Мүҗтәһид фи иш-шәргый. Башкача әйткәндә, бу - мүҗтәһид мотлак (камил, тулы). Моңа охшаш мүҗтәһидләр Коръән һәм Сөннәт нигезендә билгеле бер ысуллар һәм кагыйдәләр чыгаралар, ә аннан соң аларга нигезләнеп шәригать мәсьәләләрен ачыклыйлар. Мондый галимнәр күп булган. Аларның иң күренеклеләре түбәндәгеләр: Әгъзам - Әбу Хәнифә, имам Мәлик, имам Шәфигый, имам Әхмәд ибн Хәнбәл, Суфьян әс-Сәүри, Суфьян ибн Үяәйни, Сәиид ибн Мүсайяәб һ. б.*

*Кайбер галимнәрнең мәзһәбләре халык арасында таралмаган, кайберсенеке таралып та, озак яшәмәгән. Мәзһәбләрнең бер өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җиткән һәм бу барыбызга да билгеле 4 мәзһәб - хәнәфи, мәлики, шәфигый, хәнбәли мәзһәбләре.*

*2. Мүҗтәһид фи ил-мәзһәб. Болары - шәригать дәлилләре нигезендә иҗтиһад кылу (шәригать кануннарын чыгару) дәрәҗәсенә ирешүчеләр. Аның мүҗтәһид мотлактан аермасы шунда: ул үзе генә ысул һәм кагыйдәләр чыгармый, ә бәлки мәзһәб имамы (ягъни мүҗтәһид мотлак) тәкъдим иткән әзер ысул-кагыйдәләргә буйсына. Мисал өчен, мүҗтәһид фи ил-мәзһәб булып Әбу Йүсеф, имам Мөхәммәд Шәйбәни, имам Мүзәни тора.*

*3. Мүҗтәһид фи ил-мәсаил. Болары - мүҗтәһид мотлак чыгарган ысул-кагыйдәләргә туры китереп, кайбер сорауларга үзе җавап бирү дәрәҗәсенә ирешкән кеше. Ул бары тик мүҗтәһид фикере билгеле булмаган сорауларга гына иҗтиһад кыла ала (әлбәттә, аның ысул-кагыйдәләре кысасыннан чыкмаган хәлдә). Мүҗтәһид фи ил-мәсаилнең иң танылганнары - Тахәви, Сәрахси һәм Кәрхи.*

*4. Мүхәрриҗ. Әлеге төркемгә кергән галимнәр иҗтиһаҗ кыла алмыйлар, ләкин алар мүҗтәһиднең тышкы яктан ике төрле мәгънә белдергән сүзләренә ачыклык кертә алалар. Мәсәлән, имам Разый һәм Җүрҗәни мүхәрриҗ булган.*

*5. Мүраҗҗиһ. Әлеге төркемгә кергән галимнәр шулай ук иҗтиһаҗ кыла алмыйлар, ләкин, дәлилләргә таянып, мүҗтәһид тарафыннан әйтелгән ике фикернең берсен сайлап ала алалар. Мисал өчен, имам Кудури һәм Һидәи авторы - имам Мәргинәни кебек галимнәр мүраҗҗиһ булганнар.*

*6. Мүмәйиз. Бу төркем галимнәре алда саналган биш төркем башкара алганга сәләтле булмасалар да, "заһир үль-мәзһәб", "заһир урриуәя" һәм "риваяән-нәдира" кебек төшенчәләрне яхшы беләләр. Башкача әйткәндә, көчлене (кауи) көчсездән (зәгыйфь) аералар. Мәсәлән, күпләргә билгеле "Мүхәтара" һәм "Кәнз" исемле китап авторлары кебек мөселман галимнәре шундыйлардан.*

*7. Мүкаллид. Сез үзегез аңлаганча, болары алда саналган алты төркем эченә кермәгән факиһләр. Димәк, мәзһәб мәсьәләләрен яхшы белгән һәм аларны үз хезмәтләрендә ышанычлы куллана алган галимнәр. Мисал өчен, имам Хәскафи ибн Габидин шушы төркемгә карый.*

*Ә шәфигый мәзһәбендә исә фикъһе белгечләре (факиһләр) 3 төркемгә бүленә:*

*1) мүҗтәһид мотлак;*
*2) мүҗтәһид фи ил-мәзһәб;*
*3) мүҗтәһид фи ил-мәсаил яки мүраҗҗиһ.*

*Аллаһ бөтенесен дә төгәл белүче.*

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**



# ШӘКЕРТЛӘР СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ



**Бөек Җиңү бәйрәме алдыннан Әлмәт мәдрәсәсе шәкертләре Бөек Ватан сугышы ветераны, Әлмәт шәһәренең хөрмәтле гражданины, Сугыш тарихы фәннәре академиясенең мөхбир-әгъзасы, III ранг капитаны Хуҗахмәтов Васил Фатих улы белән очрашты.**

Васил абый күптән түгел үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үткән. Өлкән яшьтә булуына карамастан, сугыш ветераны әле дә хәрәкәттә - ул җитәкчелек иткән иҗтимагый оешма республикабызда алдынгылардан исәпләнә.

Мәскәүдә үткәрелгән Җиңү парадларында ике тапкыр катнашкан Васил Фатих улы Тын океан флотында хезмәт итүе, Төньяк Корея портларын азат итүе турында сөйләде. Шәкертләр ветеранны кызыксынып тыңлады: аннан Бөек Ватан сугышы, шул чорның бөек кешеләре, Җиңү турында сораштылар.

Васил Хуҗахмәтов шәкертләргә төпле һәм үтемле киңәшләрен бирде: батыр һәм гадел булырга, кыенлыклар һәм сынаулар алдында коелып төшмәскә, ә иң мөһиме - Кеше булып кала белергә. Нәкъ менә бу киңәшләр кайчандыр аңа үзенә авыр сугышны кичәргә, ярты гасырдан артык халыкка хезмәт итәргә ярдәм иткән.

Шәһәребезнең ихтирам казанган кешеләре белән мондый очрашулар Әлмәт муниципаль районы башлыгы Мәҗит Салиховның Р.Фәхретдин исемендәге Әлмәт мәдрәсәсенә зур игътибар күрсәтүе нәтиҗәсендә тормышка ашты. Барлык дини бәйрәмнәр, җәмәгать эшлеклеләре белән очрашулар, массакүләм мәгълүмат чаралары катнашында ачык дәресләр һ. б. аның булышлыгы белән үткәрелә. Әлмәт мөселман мәдрәсәсе директоры Энҗе Хәсәнова район башлыгының мәдрәсә шәкертләрен рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләүдә әйтеп бетергесез зур өлеш кертүен ассызыклый.

***Айрат ГАТАУЛЛИН,***
***Әлмәт шәһәре***

# МӘКТӘПЛӘРГӘ ЯҢА ФӘН КЕРТЕЛӘ

**- 2012-2013 нче уку елыннан Россия мәктәпләрендә IV сыйныф укучылары өчен "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" ("Основы религиозных культур и светской этики") дигән яңа фән кертеләчәк. Бу - илдәге традицион дин әһелләренең ил җитәкчелегенә гозере буенча эшләнә, - дип яза www.tatar-inform.ru сайты. - Ата-аналарга "Дөньяви этика нигезләре", "Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре", шулай ук православие, ислам, будда, яһүд мәдәнияте нигезләре тәкъдим ителә. Алар алты модульнең берсен сайлап алырга тиеш булачак.**




**ШУЛ** уңайдан 4 май көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә "Урта мәктәптә диннәр мәдәниятләре һәм дөньяви этика нигезләрен укыту: сәбәпләре, хыялны тормышка ашыру алымнары, көтелгән нәтиҗәләр" дигән темага "түгәрәк өстәл" утырышы узды. Очрашуда РИУ ректоры, диннәр мәдәниятләре һәм дөньяви этика нигезләре курсы буенча дәреслек авторларының берсе Рәфыйк Мөхәммәтшин, мөфтиятнең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов, Казанның будда җәмгыяте, Рус православ чиркәве вәкилләре, педагоглар, КФУның "Диннәрне өйрәнү" кафедрасы мөдире Валерий Королёв катнашты.

Сүз әлеге курсны укыту өчен кадрлар әзерләү, аларның сыйфаты, теге яки бу модульне сайлап алу, диннәр белән бәйле модульләрнең нигә быел сайланмау мәсьәләләре тирәсендә барды. Мәктәпләргә әлеге курсны кертү өчен җаваплы булган Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре килмәү сәбәпле, кадрларга бәйле күп сораулар җавапсыз да калды. Бары тик быел мәктәпләргә "Дөньяви этика нигезләре", "Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре" модульләре кертеләчәге генә билгеле булды. Әлеге курс буенча Россия төбәкләрендә үткәрелгән тәҗрибә нәтиҗәләре күрсәткәнчә, укучыларның ата-анасы күбрәк (42 %) "Дөньяви этика"га өстенлек биргән.

"Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" курсы федераль компонент буларак мәктәпләргә кергәнче, ике ел дәвамында Россиянең 19 төбәгендә (Татарстан анда катнашмады) тәҗрибә үткәрелгән.

Казан (Идел буе) федераль университетының "Диннәрне өйрәнү" кафедрасы мөдире, фәлсәфә фәннәре кандидаты Валерий Королёв билгеләп үткәнчә, яңа курсны укыту өчен кадрлар пробелмасы кискен тора. Аның сүзләренчә, аларның кафедрасы әзерләгән профессиональ белгечләрне мәктәпләргә алырга атлыгып тормыйлар. "Хәзерге вакытта мәктәп укытучыларын тиешенчә әзерләү турында уйларга кирәк", - диде ул.

Казандагы Будда үзәге президенты Оскар Брейтман сүзләренә караганда, укучыны яшьтән дөньякүләм диннәрне өйрәнүгә көчләп этәрү кирәк түгел. "Аны кеше олы яшьтә хәл итәргә тиеш. Кече яшьтән аңа көчләп тагу аның мөмкинлекләрен чикли, сәләтләре ачылмауга китерергә мөмкин. Икенче яктан караганда, без күпмилләтле илдә яшибез. Шуңа күрә күршеңнең ничек яшәве турында белү гражданлык бурычы булып тора. Диннең үсешен дөньяви күзлектән чыгып аңлатуны дөрес адым дип саныйм", - диде ул.

Казан епархиясе вәкиле Сергий Шкуро белдергәнчә, яңа предметны мәктәпләрдә махсус әзерлекле дин белгечләре укытырга тиеш. Әгәр дә мондый мөмкинлек булмаса, тарих укытучылары белем бирсә дә ярый.

Татарстан мөфтиятенең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире, тарих фәннәре кандидаты Вәлиулла хәзрәт Якупов мәктәпләргә яңа курс кертелүне хуплап, аның ярдәмендә күп кенә мәсьәләләрне хәл итеп булачагын билгеләп үтте.

Очрашуда катнашучылар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре катнашында тагын бер тапкыр фикер алышырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килде.

Шунысын да билгеләп узасы килә: диннәр тарихы нигезләрен укыту Татарстан өчен яңалык түгел. Моннан 5-6 ел элек министрлык теләге буенча диннәр тарихы буенча дәреслек эшләнгән иде. Ул Россия төбәкләренә дә тәкъдим ителде. Әлеге дәреслек буенча Татарстанда өч йөздән артык мәктәптә факультатив һәм электив рәвештә дин дәресләре укытылды. Министрлык мониторингыннан күренгәнчә, аның нәтиҗәләре бик кызыклы булып чыккан. "Балалар тарафыннан да, ата-аналар ягыннан да "Диннәр тарихы" дәреслегенә дә, аны укытуга да каршылар бөтенләй булмады диярлек", - диде РИУ ректоры.

Профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин мәктәпләргә дәреслек әзерләүдә катнашкан. "Хәзер без V сыйныф өчен дәреслек әзерлибез. Дәреслек - әле ул эшнең уннан бер өлеше генә. Педагоглар өчен өстәмә материал булу да бик мөһим. Укытучыларны әзерләү Мәгариф һәм фән министрлыгы өчен мөһим проблемаларның берсе дип саныйм. Аннан соң объектив укыту мәсьәләсе дә бар. Без татар булгач, безгә традицион ислам дине якын. Татар кешесе укытса, аның православ диненә мөнәсәбәте нинди булыр? Субъектив булмасмы дигән сораулар да бар. Укытучылар теге яки бу динне бар күңеленнән аңлата алырмы? Монда әле бик күп концептуаль мәсьәләләр бар. Бу укытыла башлагач баш калкытыр һәм акрынлап хәл дә ителер инде. Беренче елда, барыбер, проблемалар күп булыр дип уйлыйм", - диде РИУ ректоры.

**Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН, сәясәт фәннәре докторы, РИУ ректоры, әлеге курс буенча дәреслек авторларының берсе:**

- Ата-аналар өчен мин моны көтелмәгән яңалык дип атамас идем. Аннан соң җәмгыятькә дин әйләнеп кайтты. Бу мәсьәлә актуаль. Шуңа күрә ата-аналарның балаларына профессиональ рәвештә дин турында сөйләүләрен телиләр, бәлки аларның үзләренең дә белемнәре җитмидер. Диннең төрле формада мәктәпкә үтеп керүе - табигый күренеш. Ул нинди рәвештә керә һәм аның нәтиҗәләре ничек булыр дигән проблема бик күп ата-аналарны борчый. Шуңа күрә ике ел дәвамында барган эксперимент нәтиҗәсендә күп ата-аналарның Россия өчен традицион диннәр тарихын һәм дөньяви этиканы сайлавы очраклы түгелдер. Ата-аналар әле мин балама үземнең бабамның динен укыта башласам, ул белем бала өчен кирәк, ләкин аңа карата башка балаларның мөнәсәбәте үзгәрмәс микән дигән уй белән шөбһәләнә. Алар, белем бирүдән бигрәк, сыйныфны бүлгәләүдән куркалар. Моның өчен кайбер җирлек тә бардыр инде.

Чөнки бала дин тарихын гына укып калмый, аның дөньяга караш системасы да формалаша. Без динне барыбер дөньяга караш системасы дип карыйбыз. Дин турында укытканда аны мәдәнияткә генә кайтарып калдырып булмый. Дин мәдәнияте турында сөйләгәндә барыбер аның дини нигезләре, догматикасы (Аллаһка ышану, Аллаһка инану) турында сөйләргә кирәк. Бу - баланың дөньяга караш системасын формалаштыру өчен бер адым. Ата-аналар, баланың караш системасы башкача формалашып, аның башка диндәге балаларга мөнәсәбәте үзгәрмәсме икән дип азмы-күпме шүрлиләр.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# МӘЧЕТЛӘР

**2012 елның 10 маенда татар мәчетләрен җимерү турындагы указ кабул ителүгә 270 ел тулды. Халкыбыз тарихында алыштыргысыз зур урын алып торган, ислам диненә каршы юнәлтелгән бу һөҗүмне халкыбыз "достойно" кичерде. Ислам диненә, мәчетләргә каршы һөҗүм дәвам иткәнлеген искә алып, бу вакыйгалар хакында кайбер вакыйгаларны искә төшереп китмәкче булам.**

Ул заманда ислам дине мөселман кешесенең рухи терәге генә түгел, ә аның яшәү рәвеше дә була: татар кешесенең гадәти тормышы шәригать кануннары буенча тәртипкә салынганга күрә, муллаларның мәхәлләләрдә халык алдында абруе зур була, чөнки ул намаз, вәгазь уку белән бергә халык өчен кирәкле башка вазифаларны да үтәгән, казый-судья да, мөгаллим дә, хәтта табиб та булган. Шуның өстенә, рус руханилары ислам динен үзенә табигый көндәше итеп тә карый, чөнки ул чорларда мөселманнарның мәҗүсиләргә рухи яктан тәэсире нәсара диненнән көчлерәк булган дисәк тә ялгышмабыз кебек. Һәрхәлдә, рус руханилары ислам дине Россиядә артык активлашудан бик шикләнгән һәм аны булдырмас өчен вакытында кирәкле чаралар күргән.

"Мөселман муллаларында гаеп табып, аларны кызганмыйча җәзаларга, гади татарлар аларга пәйгамбәрләргә ышанган шикелле ышануны бетерү һәм мөселман санын киметү нисбәтеннән аларны Уфа һәм Казан өязләреннән сөргенгә сөрергә. Мөселман руханиларын мәчет-мәктәпләрдән алып, гарәп-фарсы телләреннән толмач итеп, халыктан аерсаң тагын да яхшырак булыр", - дип язган XVIII гасырның утызынчы елларында Оренбург комиссиясенең беренче җитәкчесе И.К. Кириллов.

Чукындыру кантуры, нәкъ менә шушы И.К. Кириллов тәкъдимнәре буенча эш йөртеп, мөселманнарның көчләп чукындыру сәясәтенә каршылыкны юкка чыгару нияте белән, рухи һәм мәдәни үзәк булган мәчетләрне җимерүдән башлый. Миссионерлар фикеренчә, мәчетләрне җимерү мөселман руханиларын юкка чыгаруга тиң булачак. Ислам диненең терәге булган руханилар юкка чыккач, дин дә югала, татар халкы динсез кала, православие динен чиксез таратырга киң мөмкинлекләр ачыла. Рус тарихчыларыннан Н.Фирсов муллаларның татар җәмгыятендә ролен болай итеп күрсәткән: "Бу мәмләкәттә ислам диненең куәте, аның халык арасында таралуы муллаларның тәэсиреннән килеп чыкканлыгы, ә алардагы тәэсир көченең, гыйбадәт урыны гына булып калмыйча, вәгазь һәм тәрбия урыны да булган мәчетләр ярдәме белән саклануы аңлашылганга, мәмләкәттә исламның бу таянычын какшату кирәк иде".

Әлбәттә, миссионерларның бу кабахәт фикере юк җирдә генә тумаган. Явыз Иван, Казанны яулап алгач та, шәһәрдә булган барлык мәчетләрне җимереп, алар урынына чиркәү салырга әмер бирә. Рус елъязмалары бу вәхшилекне болай дип теркәп куйганнар (русча бирәбез): "Божию милостию и православного царя Ивана Васильевича великою верою по его желанию сердечному прадеде ему господь бог безбожных татар казанских и бесерменскую их веру благочестивый их государь разори, и мизгиты (т. е. мечети. - Ф.И.) их розсыпа и попра, и мрачныя их места своим благочестием просвети и божии церкви воздвигнув и православие устрои и архиепископию и многие священства по церкви учини". Казанның берничә урынына Мөдһеш Иван үз кулы белән тәреләр хач утыртып, биредә чиркәүләр төзергә боера. Башкаланың үзәге Кремльдә Россия патшасы күрсәткән урында төзелгән Благовещение соборы бүген дә эшли.

Классик тарихчыбыз, оригинал фикер иясе Ризаэддин Фәхреддин фикеренчә, "Өлкәне басып алганнан һәм тырнакларын батырганнан соң, руслар мәчетләрне, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ваттылар, җимерделәр, Изге Коръән һәм башка китапларны яндырдылар. Язулы кәгазь һәм дәфтәрләрдән берсе дә калмады. Казан шәһәре алынганнан соң руслар бөтен авылларда йөреп байлыкны басып алдылар, мәктәп-мәчетләрне яндырдылар, бик күп мөселманнарны чукындырдылар. Керәшен нугае, мәкрүһ дип йөри торган халыкларның күбесе - шул вакыттагы чукындырылган халыклар... Казан хөкүмәте бетү белән... гыйлем әһелләре Кавказга һәм Төркестанга качты. Кайбер авылларда кечкенә генә һәм күбесе яшерен рәвештә гыйбадәтханәләр ачылды, муллалар барлыкка килде. Абыз ага дип йөртелә торган бу муллалар ир һәм кыз балаларны үз өйләренә җыеп иман һәм намаз да өйрәтәләр иде".

XX гасыр башында яшәгән рус тарихчысы Н.А. Спасский язуларына караганда, хан сараенда җимерелгән дүрт мәчет урынына Благовещение соборы төзелә. Явыз Иван әмере буенча Кремльдә җимерелгән мәчет урынына изге Киприан һәм Иустин чиркәве салына. Кол Шәриф мәчете урынына Спас-Преображенское монастыре төзелә башлый. Кремльдә булган биш таш мәчетләрдән берсе генә ватылмый кала. XVIII гасырда бу мәчетне чиркәүгә әйләндерәләр. Шушы мәчет тарихта Нурали мәчете исемендә билгеле.

Хәзер инде чыганакларга таянып татар мәчетләрен җимерү турында фактлар китерик. Күп кенә галимнәр мәчетләрне вату 1742 елның 19 ноябрендә сенат чыгарган указ буенча тормышка ашырыла дигән фикердә торалар. Указ Казан, Себер, Әстерхан, Воронеж губерналарында рөхсәтсез төзелгән мәчетләрне җимереп ташларга һәм яңаларын төзмәскә боера. Бу фәрман буенча, мөселманнар яшәгән авылларда бер генә керәшен булса да, мәчетләр җимертелергә тиеш була.

Ә чынбарлыкта татар авылларында мәчетләрне җимерү ярты ел алдан, синод тарафыннан шул ук елның 10 маенда кабул ителгән указ нигезендә башлана. Мәчетләрнең язмышын Казан епископы Лука Канашевич үзе генә хәл иткәнлектән, мәчетләрне саклап калу мөмкинлеге бөтенләй диярлек юкка чыга. Бу хакта Казан епископы үзенең һәрбер приходына махсус указ юллый: "Нигде вновь мечетей не было и построенные за запретительными указами мечети, где еще не разобраны б были, а так же о возобновлении вновь мечетей с согласия от него быть уже не следует". Башка епархия җитәкчеләре дә нәкъ Лука атакай шикелле эш итеп, мәчетләрне җимерүне оештыралар.

Шушы указларны алу белән татар авылларында мәчетләрне, мәдрәсәләрне җимерү, рәхимсез вату башлана. Татар авылларына нур биреп торган мәчетләрне, рухи вә мәгърифәт үзәкләрен җимерү шаукымы табигать афәте сыман үтә, әмма моңа табигать түгел, ә исламны күрәлмау сәбәп була. Бик аз вакыт - бары тик 1742-1743 елларда Казанда һәм өяздә 536 мәчетнең - 418 е, Себер губернасындагы Тубылда, Тарада һәм башка өязләрдә 133 мәчетнең - 98 е, Әстерхан губернасында 40 мәчетнең 29 ы ватыла. Мәчетләрне җимерү вакыты - бер ел! Татарча язма җыентыкта бу афәт болай тасвирлана: "Мең дә ети йөз дә кырык өчтә мәсҗидләр бозылды, аз калды. Ат елы ирде, Пётр кызы Елизавет шаһ ирде. Соң кири ясамага улук әмер итте. Алаһының әмере илән".

Биредә китерелгән саннар хакында аерым аңлатма биреп китү зарур дип уйлыйбыз. Моңа кадәр басылган тарихи хезмәтләрдә 418 җимерелгән мәчетләр саны Казан губернасында җимерелгән итеп тасвирлана. Тик бу фикер дөрес түгел. Без яңа чыганакларга таянып мондый фикергә килдек:

# ЯЗМЫШЫНДА – ТАТАР ЯЗМЫШЫ




күрсәтелгән сан Казан Татар бистәсендә һәм Казан өязендә җимерелгән мәчетләргә генә карый, биредә сүз бөтен губерна турында бармый. Бу хакта Казан епископы Лука Канашевичның 1743 елның 18 ноябрендә синодка юллаган белдермәсе яхшы дәлил булып тора. Бу белдермәдә сүз Казан өязе һәм Казандагы Татар бистәсе турында гына бара: документта беренче мәртәбә җимерелгән мәчетләрнең саны да атала.

Күптән түгел без Мәскәүдәге Россиянең борынгы чыганакларны саклау үзәк архивында (РГАДА) Казан өязендә һәм Казанның Татар бистәсендә җимерелгән татар мәчетләре исемлеген таптык. Бу исемлеккә сүз Казан татар бистәсендә һәм Казан өязендә булган 536 мәчетнең 418 е җимерелеп, 118 е генә калуы турында бара. Казандагы Татар бистәсендә ул вакытта 342 хуҗалык булып, анда 665 ир-ат яшәгән һәм биредә дүрт мәчет булган. Дүрт мәчетнең икесе Казан ханлыгын алганчы ук төзелү турында бистә халкы әйтүгә карамастан, барлык мәчетләр дә җимерелә.

Ул заманда Казан өязе элекке Казан ханлыгы традициясен дәвам итеп биш юлга бүленгән булуы тарихчыларга яхшы билгеле. Бу документта да Казан өязе шулай итеп күрсәтелгән. Казан өязе Галич юлы буенча - 17, Алат юлы буенча 91 мәчетнең барысы да ватыла, Җөри юлындагы 97 мәчетнең 96 сы, Ногай юлында 83 мәчет җимерелә, ә 52 се калдырыла; Арча юлында 127 мәчет җимерелә, 65 е сакланып кала. Ничек итеп Арча һәм Ногай юлына караган авылларда мәчетләрне саклап калырга мөмкин булуын хәзергә аңлап булмый. Мәчетләре җимерелгән кайбер авылларны атап китик: Галич юлында Котлыбулат, Кулбаш, Чуаш авыллары; Алат юлында Ябынчы, Олы Сәрдә, Әтнә, Ташкичү, Кенәр, Куныр авыллары; Җөри юлында Арташ, Кече Кирмән, Баландыш, Иске Җөри авыллары; Ногай юлында Әлки, Ибрай, Елховой, Баграж, Шахмай, Әлмәт авыллары; Арча юлында Түбән Симет, Сатыш, Янгул, Казиле, Югары Мәтәскә, Кырлай, Сикертән авылларында мәчетләр җимерелә, ә Югары Симет, Мәңгәр, Казанбашта - ике, Түбән Мәтәскәдә, Урта Пошалымда, Югары Корсада мәчетләр ватылмаган. Шунысы игътибарга лаеклы - 7-8, хәтта 4 йорты гына булган авылларда да мәчетләр эшләп килгән. Казан губирна кәнселәрендә төзелгән шушы документ җимерелгән мәчетләрнең санын дөрес күрсәтә торган иң мөһим дәлил булып тора.

Кызганыч ки, соңрак бу сан ни сәбәптәндер, рәсми документларда бөтен губерна саны итеп күрсәтелә башлый. Ә бит биредә татарлар күп яшәгән башка өязләр күрсәтелмәгән. Һәрхәлдә, бу сан Россиядә, Идел-Урал якларында миссионерлар тарафыннан кылынган вәхшилекнең чын масштабын күрсәтми. Оста куллы татар-мөселманнар тарафыннан төзелеп, авылларда иман нуры таратып торган мәчетләр Россия империясенең барча төбәкләрендә дә күпләп җимерелә һәм аның саны күрсәтелгән саннарга караганда ким дигәндә 2-3 мәртәбәгә артык булырга тиеш.

Тагын шуны күрсәтеп китү кирәктер дип уйлыйбыз: мәчетләрне җимерү ислам динен татар халкы арасында какшатуга китерми; киресенчә, ул православие миссионерларының кылган эшләренә нәфрәт уята; ә татарлар үзләрен керәшеннәр белән бутамас өчен, башка халыклар белән танышканда үзләрен мөселман дип атый башлыйлар. Алар арасында чукынучылар саны да бик артмый, елына 100-150 тирәсе. Татарлар арасында чукынучылар саны 1748-1749 елларда гына бер меңнән артып китә.

Мәчетләрне төрле төбәкләрдә җимерү хакында берничә мисал китерәбез. Вятка епископы Варлаам атакай Слободской өязендәге Зур авыл, Ильяс, Починошной, Чепца өязендәге Кыстым авылында булган мәчетләрне ватарга тәкъдим итә. Кызганыч ки, без бу епископның теләге үтәлгәнме, әллә юкмы икәнлеген ачыклый алмадык. Шулай да бу авыллардагы Аллаһ йортлары җимерелгәндер дип уйлыйбыз, чөнки рус руханиларының мәчетләрне юкка чыгару теләге вакытында тормышка ашырылган.

1753 елда Касыйм шәһәрендә Дмитрий Симонов исемле бер алпавыт элек татарлар биләмәсе булган урында җир сатып ала. Бу алпавыт җирендә таш мәчет сакланып калган була. Дмитрий Симонов мәчет материалларыннан чиркәү төзү өчен Рязань епископы Палладийдан рөхсәт ала һәм үзенең кешеләрен мәчетне ватарга җибәрә. (Игътибар итегез: рөхсәтне мөселман мулласы түгел, ә православие рухание бирә!) Тик алар тиз арада таш мәчетне ватып бетерергә өлгерә алмыйлар. Кылынган вәхшилек турында ишеткән касыйм татарлары морза Абдулла Маметов җитәкчелегендә мәчет тирәсендә җыелалар һәм ачудан мәчетне ватучыларны кыйнап та ташлыйлар, ә берсенең кулын бәйләп Касыйм кәнсәләренә алып киләләр. Тик соңыннан барыбер бу мәчетне ватып, аның материалыннан руслар чиркәү төзеп куялар.

Нижгар губернасы Курмыш өязендәге Маклаковка авылында булган мәчет 1760 елда юкка чыгарыла. Мәчетне ватканда татарлар каршылык күрсәтмәсен өчен авылда гаскәриләр командасы "тынычлык" саклап тора.

Төрле төбәкләрдә мәчетләрне җимерү кызган вакытта, 1742 елның сентябрендә үк Казанның Татар бистәсе мөселманнары исеменнән Сәфәр Гомәров исемле изге зат патшабикә Елизавета Петровна исеменә үтенеч юллый. Аның фикеренчә, татар бистәсендә мәчетләрне ватарга нигез юк, чөнки бистәдәге мәчетләрне вату турында указда махсус әйтелми, керәшеннәр Татар бистәсендә яшәми, рус чиркәүләре биредә юк, ә Татар бистәсе руслардан аерым урнашкан. Әлбәттә, бу үтенеч мәчет төзәргә рөхсәт алырга мөмкинчелек бирми. Киресенчә, 1742 елның 19 ноябрендә сенат кабул иткән указ шушы мөрәҗәгатькә җавап була да инде.

Татарлар хакимият органнарына җимерелгән мәчетләрне торгызу өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать итеп торалар. Беренчеләрдән булып, сенатка Казан өязе Төбәк авылыннан Бакый Исмәгыйлев, Зөя өязе Олы Шырдан авылыннан Айтуган Ураскиев, Сембер өязе Мочалы авылыннан Мәхәммәтали Мәхәммәтев, Пенза өязе Түбән Елзан авылыннан Давыт Кудашев мәчетләрне яңадан торгызу мөмкинлеген үтенәләр. 1743 елда, Казан, Зөя, Сембер өязләрендәге ясаклы татарлар миссионерлар җимергән мәчетләрне торгызу кирәклеге турында патшабикәгә шикаять язалар. Сенат: "Хәзергә кадәр мәчетләр сакланып калган булса, аларны ватарга, яңаларын төзергә рөхсәт итмәскә, татар авылларында чукынганнар арасында чукынмаганнар булса, аларны икенче авылларга күчереп утыртырга!" - дигән фәрман чыгара.

Шулай да, бу указда Казандагы Татар бистәсендә, Казан һәм башка губерналарда җимерелгән мәчетләр урынына, мәхәллә 200-300 кешедән торса, мәчет салырга рөхсәт бирә. Шул ук вакытта яңа мәчетләр төзүне булдырмау өчен хакимият татар абызларыннан һәм йөзбашларыннан махсус имзалар ала. Тик бу сенат фәрманының мәчетләр төзү рөхсәте ул елларда тормышка ашырыла алмый, чөнки ул вакытта татарларны дини изү шулкадәр көчле була ки, алар сенат яисә синодка мәчет төзергә рөхсәт бирегез дигән үтенечкә һәрвакыт: "Мәчетләрне җимерергә!" - дигән карарлар чыгып кына тора. Безнеңчә, указның мәчетләрне төзергә мөмкинлек биргән өлеше татарларга бөтенләй җиткерелмәгән булырга тиеш...

Казан һәм Сембер өязләреннән йомышлы морзалар һәм татарлар исеменнән Якуб Биметев 1744 елның 13 апрелендә сенаттан мәчетләр төзергә рөхсәт сорый. Бу сорауга сенат: "Сакланып калган мәчетләрне ватарга, яңаларын салмаска, ә мөселманнарны икенче авылларга күчерергә!" - дигән фәрман кабул итә.

Россия империясе составында булган мөселманнар арасыннан XVIII гасыр буенча туктамыйча баскыннарга каршы баш күтәреп торган башкортларга гына мәчетләр тотарга рөхсәт ителә, биредә булган мәчетләр рәсми җимерелми; шундый өстенлекләр булуга карамастан, 1744 елның 20 февралендә чыккан фәрман буенча Уфа өязендә, башкорт ягында, яңа мәчетләр төзү барыбер тыела.

Ә татар-мөселман халкы, Россия хакимияте рөхсәтен көтеп тормыйча, җимерелгән мәчетләр урынына яңа мәчетләр төзи башлый. Нәкъ шушы елларда, миссионерлар күзенә чалынмасын өчен, манарасыз мәчетләр эшләнә башлый. (Руслар аны рәсми документларда "пятивременные мечети", ягъни биш вакыт намаз укый торган мәчет дип теркәгәннәр).

Беренчеләрдән булып Казан өязе, Ногай юлы Елтан, Агрызан, Ясаклы Көек, Зур һәм Түбән Шантала авылларында 1744 елда җимерелгән мәчетләр урынына яңалары салынган була. Казан өязе, Ногай юлы Әлки авылы йомышлы татарлары исеменнән Әнишә Барисов, сайланган (выборный) Мәкәй Мәмәев, староста Али Чапкынов 1744 елда авылларында ватылган мәчет урынына яңаны төзергә рөхсәт сорыйлар. Мондый хәбәрне алу белән рус миссионерлары бу төбәктә зур тикшерү ясыйлар. Тикшерү татарларның бернәрсәдән дә курыкмыйча еракта булган авылларда гына түгел, ә рус авылларыннан якында да рөхсәтсез мәчет төзүләре турында күрсәтә. Бу башбаштаклыкны күргән миссионерлар тагын "мәчетләрне кичектергесез ватарга, яңаларны салырга рөхсәт итмәскә, ә татарларны рус һәм керәшен булмаган авылларга күчереп утыртырга!" - дигән фәрман кабул итәләр.

Татарлар формаль юридик яктан мәчет төзү өчен рөхсәтне 1743 елда алсалар да, бу указны тормышка ашыру өчен күп еллар хакимият белән көрәшергә туры килә. Рәсми рәвештә татар авылларында 200 хуҗалык булган очракта мәчет төзергә рөхсәтне сенат 1756 елда, Батырша восстаниесе шаукымы астында гына кабул итәргә мәҗбүр була. Казандагы Татар бистәсендә мәчет төзәргә рөхсәт 1743 елда бирелсә дә, аларга Аллаһ йортын салу өчен 25 елга якын шәһәр түрәләре һәм миссионерлары белән көрәшергә туры килә.

Казанга кунакка килгән Әби патша - Екатерина-Сания генә 1767 елда Татар бистәләрендә таш мәчетләр салырга рөхсәт бирә. Бу хакта риваятьләрдә балай теркәлгән: "Әби патша Казанга килгәч, мөселманнарның олуг байлары Әби патша катына кереп гарызнамә биргәннәр, бистәгә таш мәчет салырга рөхсәт сорап. Вә һәм Әби патша, Казан байларының гарызын кабул итеп, таш мәчет салырга рөхсәт биргән вә һәм мәчет урынын тәгаен кылган, вә һәм мөселманнарны бик яраткан; Казанда торган мөддәтендә һәммишә (һәрвакыт, өзлексез) мөселман арасына төшеп: "Рустан җәфа күрмимсез?" - дип сорашып йөргән". (Бу вакытта инде Татар бистәсе уртасына рус чиркәве салып куелган, берничә керәшен гаиләсе мөселманнар арасына күчерелеп утыртылган, 200 бала укый торган керәшен мәктәбе ачылган). Патшабикәнең карары булуга карамастан, татарлар 1773 елда яңадан төзелгән мәчетлерне руслар җимерергә исәпли, чөнки: "Рөхсәт телдән генә әйтелгән иде", - дип яңадан шикаять язарга мәҗбүр булалар.

Чукындыру кантуры миссионерлары мәчетләрне вату, җимерү белән беррәттән Идел буендагы керәшен авылларында чиркәү һәм монастырьлар салу эшен киң җәелдереп җибәрәләр. Керәшен авылларында чиркәүләрне күп итеп төзүне архимандрит Димитрий Сеченов башлый. Башта ул авылларда 30 чиркәү төзүне сорый. Сенат фәрманы чиркәүләр керәшен авылларында гына түгел, ә чукынырга теләмәгән мөселман-татар авылларында да төзү, төзелешкә мөселман татарларны да җәлеп итү кирәклеген күрсәтә.

Лука Канашевич тәкъдиме белән чиркәү, монастырьлар нигезен салганда борынгы татар зиратларындагы каберташлар киң кулланыла. Шулай итеп халкыбызның борынгы гореф-гадәте, теле һәм мәдәнияте ядкярләре вәхшиләрчә юк ителә, чиркәүләргә күп еллар буе нык нигез булып хезмәт итә. Бу хакта бер гыйбрәтле мисалны Мәрҗани хәзрәтләре дә китерә: "Моннан җитмеш еллар элек Әтрәчтән биш чакрым көньяктарак урнашкан Җанбакты исемле рус авылы алпавыты шул авылга чиркәү салдырганда, нигезенә таш кирәк булгач, шундагы тигез ташларны кулай табып, мөселманнарның олылап хөрмәт иткән ташларыннан егерме-утызлабын агач чиркәүнең нигезенә куйдырган. Әтрәч авылының яше сиксәннән узып барган мөәзине түбәндәгеләрне сөйләде: "Мин бала чагымда атам белән шул авылга йомыш белән барганда ул ташларны төзәтеп куйганнарын карап тордым. Атам елап: "Менә, балам, безнең авылыбыздагы газизләрнең каберләре өстендәге ташларны чиркәү бусагасына куялар, - дип әйтте".

Казан һәм Воронеж губерналарында 1747 елда гына да 88 чиркәү төзелә, ә тагын 22 не төзергә кирәк дип табыла. Күпләп көчләп чукындыру чорында керәшен авылларында барысы 241 чиркәү казна исәбенә төзелә. Казан епархиясендә 1740 елда 669 чиркәү булса, 1745 елда алар саны 725 кә җитә. Димәк, биш елда 56 храм төзелә. Ул чорда Казан епархиясенә Арча, Лаеш, Зөя (Свияжск), Козмодемьянск, Чабаксар, Царевококшайск, Тәтеш, Сембер, Оса, Сарапул, Кукарка, Царевочансурск, Малмыж, Алабуга, Уржум, Яранск, Ветлуга, Уфа, Бөре, Самара, Оренбург, Сергиевск, Ставрополь (хәзерге Тольятти), Җаек шәһәрләре һәм өязләре кергән була.

Татар-мөселманнар, мөмкинчелектән файдаланып, җимерелгән мәчетләрне торгызу өчен зур көч һәм тырышлык куйганнар. XVIII гасырның 60-70 нче елларында ук шактый авыллар мәчетләрен төзеп, мәктәп-мәдрәсәләр эшен дә рәткә сала алганнар. Данлыклы рус академигы И.Лепехин шул заманда Чирмешән якларындагы татар авылларын карагач һәр авылда мәчет һәм мулла булуын, ә авыллар зур булган очракта, аларның саны ике-өчкә җиткәнен дә күрсәтеп үтә. Бу ук хакта шулай ук Пётр Рычков язмалары да сөйли. Ул да һәрбер авылда диярлек мәчет, мәктәп булганлыгын, биредә малайлар гына түгел, кызларның да татар, гарәп теленә, Коръән серләренә өйрәнүе турында сокланып яза.

**Фәйзелхак ИСЛАЕВ,**
**тарих фәннәре докторы,**
**Татарстанның Мәгарифне үстерү институты профессоры**

# Ислам мәгарифенең әһәмияте, аның хәзерге торышы һәм киләчәге

***Безнең көннәрдә илебез җәмгыяте тормышында диннең роле арту, конфессияләр яшәешенә дини мәгариф һәм мәгърифәт үтеп керү, көнкүрешебездә мәгариф институтының трансформацияләнүе сәбәпле дини мәгариф белән кызыксыну арта бара. Россия күпмилләтле дәүләт буларак танылган. Бездә "яшәүче" диннәрнең күп санда булуы буенча Россия - уникаль ил. Илебездә бөтен дөньяга таралган диннәрнең барлык дәвамчылары да (ислам, христиан (православие, католицизм, протестантизм), будда, яһүд диннәре) үзара татулыкта һәм тынычлыкта яши. Нәкъ менә шуңа күрә мәгариф системасын өйрәнү зур әһәмияткә ия.***

Мөселман мәгарифе барлыкка килүнең иң башлангыч стадияләрен күзәтеп, шунысын да билгеләп узасым килә: Россиядә көчләп чукындыру сәясәте "көтелгән" нәтиҗәләр бирә алмады һәм мөселман халкының күпчелеге үз динендә калды. Бу уңайдан, император Екатерина Икенчегә аерым басым ясап узасым килә. Ул мөселман факторын юк итү адымына бармаска карар кыла һәм мәсьәләләрне безнең файдага хәл итә. 1773 елда ул Уфада "Оренбург Диния нәзарәте төзү турында" указ ("О создании Оренбургского магометанского духовного собрания (ОМДС)") чыгара һәм ислам динен тигез хокуктан мәхрүм итү, кимсетү туктатыла. Чөнки XVIII гасырга кадәр мәктәп һәм мәдрәсәләр эшчәнлеге турында телгә алынмый, ә Диния нәзарәте төзелгәннән соң "алар каршында мәчетләр төзергә һәм мәдрәсәләр ачарга рөхсәт ителә". XVIII йөзнең 70 нче елларында Казанда өч мәдрәсә барлыкка килә (Ахундов, Апанаев, Әмирханов мәдрәсәләре), шулай ук Кышкар (хәзерге Арча районында. - ред.), Мәңгәр (хәзерге Әтнә районында. - ред.), Сатыш авылында (хәзерге Саба районында. - ред.) һәм Сабада белем үзәкләре ачыла... Мәдрәсәләр Уфада да, Оренбург өязендә дә булган. XVIII гасыр ахырына таба барлык татар авылларында да диярлек мәчетләр һәм алар каршында мәктәпләр эшли, ә "XIX йөз уртасына бары тик Казан краенда гына да 430 мәктәп һәм 57 мәдрәсә исәпләнә".

Урта Идел буендагы төрки телле халыклар арасында уку йортларының сан ягыннан кисәк кенә артуы - мәгариф системасының хәтта мөселманнарны эзәрлекләү һәм аларның динен кысу елларында да яшәп килгәнлеген күрсәтә. Югыйсә, кыска вакыт эчендә барлык мәктәп һәм мәдрәсәләрнең мөгаллимнәр белән ни рәвешле тәэмин ителеп бетүен башкача аңлату кыен. Аларның күпчелегендә уку-укыту яшерен һәм рәсми булмаган булып кала бирә, әмма, барыннан да бигрәк, әлеге процесслар буенча барысын да эченә ала торган тикшерү дәүләт ягыннан булмаган. Укытуның төп формасы суфи шәех һәм мөрид - аның укучысы арасындагы үзара мөнәсәбәтләр белән белдерелгән суфичылык характерын саклаган.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Ислам мәгарифенең әһәмияте, аның хәзерге торышы һәм киләчәге

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Моңа мөнәсәбәттә тикшерү өчен шактый кызыклы булып абызагайлар хәрәкәте (XVIII гасырда хәтта грамотасыз кешеләрне - ислам дине нигезләрен, Коръәннең кайбер аятьләрен белүчеләрне һәм хәреф-язу таныганнарны шулай атаганнар) күз алдына килеп баса. Алар мөселман традициясе һәм укымышлылыгын саклап калучылар сафында торган. Абызагайлар хәрәкәте үзе генә үзәкләшкән көч хасил итмәгән, ә бәлки аерым авыл общиналары (үзидарә оешмасы) эчендә тупланган. Ул Казан ханлыгы чоры дин башлыклары һәм Оренбург мөселманнары Диния нәзарәте руханилары арасында "бәйләүче буын" булган.

Общинаның автоном башлыгы буларак сайланучы имам төшенчәсе рәсми билгеләнә торган имамга каршы булган - бу исә татар халкының дин тарихында суфичылыкның ролен тагын бер тапкыр ассызыклый. Үрнәк болгар дәүләте идеяләре суфичылык белән укмашып, татар халкы арасында хөкүмәткә каршы булган акция чараларының берсен абызагайлар хәрәкәте тәшкил итә (мисалга 1667-1671 елларда Степан Разин һәм 1775 елда Батырша восстаниеләрен яклаган чыгышларны китерергә мөмкин).

**(Ахыры газетабызның киләсе санында.)**

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы,**
**республикабызның көньяк-көнчыгыш төбәге казые**


# Вәсвәсә уйлардан арына алмыйм...

***Мин үзем өчен бик тә мөһим булган бер сорау бирергә телим. Мине еш кына котчыккыч уйлар җәфалый (бу турыда хәтта сөйлисем дә килми). Алар мине чын мәгънәсендә бетереп ташлыйлар. Мондый уйлар минем бар тормышымны боза.***

***Кайчакта алар башымнан хәтта намаз вакытында да чыкмый, күңелемнән бер дә китми. Миңа ул уйлар турында сөйләргә бик оят. Элегрәк мин аларның нилектән минем башымда урын алырга мөмкин булуын белмәдем, белергә дә теләмәдем, үземне: "Мин бит мөслимә, бетәр әле", - дип юаттым. Гомер узган саен боларның барысы да шайтанның котыртуы аркасында икәнлеген аңлый төшәм. Мин иң әүвәл моңа охшаш уйлар бары тик мине генә борчыйдыр дип уйлап йөргән идем, әмма соңыннан шуңа да төшендем: моннан барлык күп кенә мөселманнар да интегә икән.***

***Минем беләсем килә: шайтанның бу рәвешле "янавы" - ул көчле иман билгесеме, әллә киресенчәме? Мин әлеге күренеш белән көрәшергә тырышып карыйм, ләкин нәтиҗәсез. Зинһар өчен, күңелемне мондый коточкыч галәмәтләрдән арындырырга ярдәм итә торган киңәшләрегезне бирсәгез иде! Алдан ук зур рәхмәтемне белдерәм.***

И., ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ




**Сезнең соравыгызга ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы, республикабызның көнчыгыш төбәге казые Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ җавап бирә:**

- Һәр кешенең вәсвәсә кылучы шайтаны - "карин"е бар. Һәм ул адәм баласын гөнаһ эшләргә котырта. Хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) дә карине булган, әмма Аллаһның рәхмәте белән ул иман китергән һәм, хәдисләрдә әйтелгәнчә, пәйгамбәребезне яхшы эшләргә генә этәргән.

Имам Әбу Давыт һәм ән-Нәсәи ибен Габбастан нәкъ сез сораган әйбергә бәйле хәдис китерәләр: "Пәйгамбәребезгә (сгв) бер кеше килде һәм әйтте: Әй Аллаһның илчесе! Минем күңелемә шундый уйлар килә, аларны кешегә сөйләүгә караганда күктән егылып төшү минем өчен хәерлерәк (ягъни андый оят уйларны сөйләүгә караганда үлемне артыграк күрәм). Пәйгамбәр (сгв) аңа әйтте: "Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Шайтанның мәкерен вәсвәсәгә генә кайтарып калдырган (ягъни аны гамәлдә эшләтмәгән) Аллаһка мактау булсын!" Бу хәдистән күренгәнчә, пәйгамбәребез ул кешене вәсвәсә өчен хурламаган, бәлки вәсвәсәдән гамәлгә әйләнмәгәне өчен Аллаһны мактарга, хәмед-сәнә кылырга өйрәтеп калдырган. Шайтанның мөселман кешегә вәсвәсә кылуы табигый хәл һәм ул намаз вакытында да булырга мөмкин. Әмма мөселман кешесе ул коткыга бирелеп аны теленә һәм гамәленә чыгармаска тиеш. Шулай булганда, вәсвәсәгә каршы торганы өчен ул савапка ирешә.

Шайтан вәсвәсәсенә каршы тору өчен Аллаһны күбрәк искә алырга кирәк, чөнки Аллаһны зекер иткәндә шайтан поса, кеше күңеленә коткы сала алмый. Коръән уку, намазлар уку, зекерләр әйтү, сәдакалар бирү, мохтаҗларга ярдәм итү, ятимнәргә, ялгызларга, юлчыларга изгелек кылу, ата-ананы тәрбияләү, олыларга хөрмәт күрсәтү кебек хәерле эшләр кешенең күңелендә вәсвәсәгә урын калдырмый. Шулай ук изге кешеләр белән, дин галимнәре белән күбрәк аралашу, явыз һәм бозык кешеләрне ташлау кирәк. "Фатиха" сүрәсен, "Ихлас", "Фәлак (Таң ату)", "Нәс (Кешеләр)" сүрәләрен, "Аятел Көрси"не ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 255 нче аяте) укып яту, үз-үзеңне шуларны укып өшкерү дә бик файдалы, чөнки Коръән тән һәм җан чирләреннән шифа булып тора. Бу дөньяга адәм баласы сынау өчен җибәрелгән һәм Аллаһ һәр кешегә үзе күтәрә алырдай сынауны гына йөкләгән. Аллаһы Тәгалә сезгә ярдәмнәрен бирсен. Ул сынауның, шайтанга каршы көрәшнең нәтиҗәсе яки мәңгелек җәннәт, яки җәһәннәм икәнен гел исебездә тотарга тиешлебез.



**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

Реклама




## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 12.05.12 | 3:07 | 4:37 | 13:02 | 18:10 | 20:44 | 22:14 |
| *Якшәмбе* | 13.05.12 | 3:05 | 4:35 | 13:02 | 18:11 | 20:46 | 22:16 |
| *Дүшәмбе* | 14.05.12 | 3:03 | 4:33 | 13:02 | 18:13 | 20:48 | 22:18 |
| *Сишәмбе* | 15.05.12 | 3:01 | 4:31 | 13:02 | 18:14 | 20:50 | 22:20 |
| *Чәршәмбе* | 16.05.12 | 2:59 | 4:29 | 13:02 | 18:15 | 20:51 | 22:21 |
| *Пәнҗешәмбе* | 17.05.12 | 2:57 | 4:27 | 13:02 | 18:16 | 20:53 | 22:23 |
| *Җомга* | 18.05.12 | 2:56 | 4:26 | 13:02 | 18:17 | 20:55 | 22:25 |
| *Шимбә* | 19.05.12 | 2:54 | 4:24 | 13:02 | 18:19 | 20:57 | 22:27 |

# Мәктәпләргә яңа фән кертелә

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Моның өчен җирлек бар дип уйлыйм. Аннан соң диннәр укыту өчен мәктәп үзе, гомумән, әзерме икән? Чөнки мәктәп - дөньяви. Мәктәптә табигать фәннәре Чарльз Дарвинның эволюция теориясенә корылган. Бер дәрестә бу теория буенча укытып, икенче дәрестә Аллаһы Тәгалә кешене яраткан дип өйрәтеп, аның нәтиҗәсе нәрсә булыр дигән мәсьәлә, әлбәттә, ата-аналарны борчый. Бу аларны гына түгел, безне дә уйландыра. Без бу курсны мәктәпкә балаларыбыз әхлаклырак булсын дип кертәбез. Кайбер нәтиҗәләр дә бар. Мәсәлән, Балтач районында ун ел дәвамында "Әхлак нигезләре" укытыла. Аның нәтиҗәләре шактый сизелә. Әхлаклылык дәрәҗәсе, дин сабагы укыганнан соң, барыбер үсә.

Биредә сүз югары әхлаклы булу турында гына бармый. Без бит күпмилләтле дәүләттә яшибез. Күпмилләтле дәүләттә ул проблема китереп чыгармасмы? Шәхсән баланы алганда, аның әхлагы югары булыр, шул ук вакытта башка балаларга карата аның мөнәсәбәте кардиналь үзгәрмәсме? Ул мөнәсәбәт җәмгыятькә проблема китереп чыгармасмы дигән сорау кала бирә. Без Татарстанны күпмилләтле, толерант дип йөртәбез. Бу фән кереп киткәннән соң, күпләр биредә кардиналь, принципиаль үзгәрешләр булмасмы дип уйлана. Бу хакта Мәгариф министрлыгы чиновниклары да хәбәрдар. Шуңа күрә быел ике генә модульнең кереп китүе дә шуның белән бәйле. Ул башка диннәр тарихларын укытырга теләмәүдән түгел, ә бәлки Татарстанда диннәр арасындагы мөнәсәбәт тискәре якка үзгәрмәсме икән дип шүрләүдән. Әмма алга таба ислам дине, православ дине нигезләрен сайлау барыбер булмый калмас. Безнең республикабызда бит тулысынча татарлар гына яшәгән районнар да бар. Анда ислам дине нигезләрен укытудан мин бернинди дә проблема да сизмим. Аннары руслар яшәгән районнарда православие дине нигезләре укытканда, сыйныфны бүлгәләү юк. Ә шәһәрләрдә укытуны оештыру ягыннан да, нәтиҗәләр хакында әйтү дә шактый четерекле.

**Римма ГАТИНА**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №19 (136) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-533.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 10 май көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллланудан сакланыгыз!**